Мирас

Сабыйга

5·6
1995

НА ТАТАРСКОМ И РУССКОМ ЯЗЫКАХ



Гамил Афзал

Язгы яңгыр

Яшел язда дымлы иртә,
Тәрәзәмә яңгыр чиртә.
Тонык күкрәү соры күктә
Еракларда яңгырап китә.

Җылы яңгыр, язгы яңгыр
Рәхәт бирә уҗымнарга,
Күңелләргә өмет сала,
Гөлләр сибә болыннарга.

Весенний дождь

Веет влагой весенней, ура!
Дождь в окно мне стучится с утра.
В небесах глас весны — смутный гул,
Окунулся в весну мой аул.

Дождик теплый, весенний, живой
Напоил озимые водой,
Все цветы разбудил ото сна,
И в душе, и в природе — весна!

Перевод **РАФИСА АХМЕТА.**

Художник СВЕТЛАНА ИБРАГИМОВА
(Рәссам СВЕТЛАНА ИБРАҺИМОВА)



Сабыйга

№ 5-6 (11-12) — 1995 г.
(май-июнь)

Балаларның
әдәби-нәфис журналы
Детский литературно-художественный журнал

УЧРЕДИТЕЛИ:

Трудовой коллектив редакции журнала «Сабыйга», Министерство народного образования РТ, редакция международного журнала «Мирас» («Наследие»), администрация г. Казани

Главный редактор
Минахмед Сахапов

Совет редакции
Ришат Абубакиров
Разил Валеев
Марс Гайнетдинов
Фердинанд Галямиев
Шаукат Галиев
Мунавир Галимуллин
Фирдаус Зарифуллин
Фарид Ишмаков
Хануз Махмутов
Аркадий Мельников
Флюн Мусин
Лилия Сахапова
Индус Тагиров
Раис Тухватуллин
Мусагид Хабибуллин
Вахит Хаков
Зуфар Хакимов
Рафигулла Хамидулла
Анас Хасанов
Рауф Хуснутдинов
Фанис Яруллин

На обложке рисунки
Ивана Воробьева

Индекс детского журнала «Сабыйга» 73954. Подписка на журнал производится без каких-либо ограничений во всех областях, краях, республиках Российской Федерации, в государствах Ближнего и Дальнего Зарубежья. Журнал выходит на татарском и русском языках. Адрес редакции: 420066, г. Казань, ул. Чистопольская, 5. Тел.: (8432) 49-35-54. По вопросам доставки по подписке обращаться по телефону 35-13-64, качества печати 49-36-62. Для спонсоров журнала: р/с № 100609617 МФО 265016 при РКЦ ГЦБ корр. счет № 700161503 в акционерном ТСБ г. Казани. Коды журнала «Сабыйга»: ОКПО 12986213, ССОГУ 8704, СОАТО 1192401365, ОКОНХ 87100. Журнал «Сабыйга» зарегистрирован в Мининформпечати РТ. Свидетельство № 314. Выходит с 1 июля 1994 года.

Сдано в производство 10.01.95 г. Подписано в печать 2.03.95 г. Формат 84 × 108¹/₁₆. П. л. 2,0 (2,1). Учетн. изд. л. 3,36. Печатается офсетным способом. Тираж 4517 экз. Заказ Д-8. Цена договорная. Типография газетно-журнального издательства. 420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2.

© «Сабыйга», 1995

ХӘРӘКӘТЛЕ УЕННАР
ПОДВИЖНЫЕ ИГРЫ

Аю-бүре





УЕН

Бу күмәк уен җәй көне тышта, җае туры килгәндә, әрәмәлек буйларында уйнала.

Балаларның берсе аю яки бүре булып берәр җирдә посып тора. Башкалары урманга «җиләк җыярга» китәләр. Берәү аларга каршы очрап, сораша:

— *Дуслар, кая барасыз?*
— Кара урманга барабыз.
— *Кара урманда нишлисез?*
— Кара җиләк җыябыз.
— *Җиләк белән нишлисез?*
— Җиләктән как коябыз.
— *Бүре килсә нишлисез?*
— Урман буйлап чабабыз.

Аннан соң барысы да күмәкләп жырлыйлар:

Җиләк җыям, как коям,
Карт әнигә бүләккә;
Монда җиләк күп икән,
Аю-бүре юк икән.

Бүре яшеренгән җиреннән сикереп чыга да аларны куа башлый. Кемне тотса, шул бүре була.

Уен йөгереклек һәм җитезлек сәләтен үстерүгә хезмәт итә.



Художник ЮСУП ВАЛИАХМЕТОВ (Рәссам ЙОСЫФ ВӘЛИӘХМӘТОВ)

Волк-медведь

ИГРА

Обычно такая игра разыгрывается летом, в теплую погоду на опушке леса, полянке или возле ручья-запруды.

Один из играющих ребят надевает маску волка или медведя, напяливает шубу наизнанку и прячется в кустах. Остальные гурьбой направляются в лес «по ягоды». Их встречает один из играющих ребят и засыпает их вопросами:

— Ну куда понес вас бес?
— В темный и дремучий лес,
Полный сказок и чудес...
— Что ж в лесу мы будем делать?
— Лес — наш добрый, щедрый дом,
Всяких ягод наберем,
И черники и брусники,
И малины и клубники...
— А затем что будем делать?
— Всем друзьям на удивленье
Приготовим им варенья,
И компот, и пастилу.
— Коли волк вам попадется?
— Разбежаться нам придется!

Затем все хором поют:

Для бабули собираем
Ягод спелых — вон их сколько.
Нет у нас в лесу медведей,
Нет у нас в лесу и волка...

Тут из-за кустов выскакивает волк и начинается погоня. Кого догонит волк, тот и занимает его место, т. е. сам становится волком.

Игра продолжается до тех пор, пока дети не устанут.

Данная игра способствует развитию резвости, смекалки, ловкости.

Перевод
РАФИСА АХМЕТА.



ДУҢГЫЗ

Кабан дуңгызы Татарстанга 1970 елда аучылык оешмалары тарафыннан китерелә. Кыска гына вакыт эчендә ул Татарстанның барлык төбәкләренә дә таралырга өлгерә. 1990 елда кабан дуңгызларының саны 2000нән артып китә. Алар хәтта авыл һәм урман хуҗалыкларына зыян китерергә дә өлгерәләр. Шуңа күрә ел саен 300гә якын кабан дуңгызы аучылар тарафыннан атыла. Кабан дуңгызы урманның үтә алмаслык куе җирләрендә һәм сазлыкларда яши, шунда туклана. Соңгы вакытта чытырманлыклар һәм сазлыклар шактый кимеде. Шул сәбәпле кабан дуңгызлары аланлыкларны сөреп чыгалар, бәрәңге басуларында, иген кырларында тукланалар, кырмыска ояларын, чытырманлыкларда яшәүче бик күп вак җәнлекләрне юк итәләр, агач төрләренең табигый рәвештә яңаруына комачаулыйлар.

Урысчадан
ЛИЛИЯ СӘХАПОВА *тәрҗемәсе.*



Кабан

Кабан завезен в нашу республику охотничьими организациями в 1970 году, расселился за короткий период практически по всей территории. К 1990 г. его численность превысила 2000 голов, стал ощущаться вред этого зверя в сельском и лесном хозяйствах. Отстреливается ежегодно до 300 голов. Кабан кормится в лесной подстилке, особенно в дубравах, а также в болотах. Площади дубрав сократились, резко сокращена площадь болот. Кабаны перепахивают целые поляны, кормятся на картофельных полях, на посевых зерновых, разрушают муравейники, уничтожают многих мелких животных в подстилке и на поверхности почвы, мешают естественному возобновлению древесных пород.



Художник АЙДАР УТЯГАНОВ
(Рәссам АЙДАР ҮТӘГӘНОВ)



Аркадий Мельников

БҮРЕК

Дәрес бетәргә берничә минут калды, ләкин балалар бер-берсен бүлә-бүлә программа буенча түгел, бәлки үз тормышымнан берәр нәрсә сөйләвемне үтенделәр. Мин аларга үземнең яшь солдат булып фронтта ничек сугышуым хакында күп сөйләдем, ләкин һәрвакыт нинди дә булса берәр яңалык белергә теләү хисе кешедә даими яши, ә балаларда исә бу сыйфат аеруча көчле:

— Ярый, балалар, күндердегез!

Мин бүрек турындагы бер вакыйганы искә төшердем. Бервакыт иртән мин тәрәзәне ачтым: салкынча иртәнге һавада карбыз исе аңкый. Днепр дулкыннары хәвефләнеп ярга бәреләләр.

Кинәт мин өй түбәсеннән биектә кара тәреле фашист самолетларын күрдем. Бомбалар коелды. Димәк, сугыш. Мин үзем теләп халык гаскәренә язылдым. Без караулда тордык, диверсант-парашютчыларны тоттык. Аларның өстендә безнең өр-яңа хәрби кием, аякларында шыгырдап торган күн итекләр, билләрендә күн каеш иде. Ике айдан соң без эшелонга хәрби заводның кыйммәтле җиһазларын төяргә һәм ерак Себер тылында снарядлар эшләүне көйләргә дигән боерык алдык. Мин үзем белән дәреслекләр һәм пәлтә белән бүрегемне генә алдым. Безнең эшелон иң соңгысы иде. Днепр аша салынган күперне үтеп кенә өлгердек, берничә шартлау тавышы яңгырады һәм күпер суга җимерелеп төште. Күперне бомбага тоткан фашист козгыннары безне Ростовка кадәр эзәрлекләп бардылар. Алар безнең эшелонны юк итәргә теләделәр, бомбалар төрле җирләрдә шартлады, ләкин аларның берсе дә эшелонга эләгә алмады.

Кырык беренче елның зәһәр кышында мәктәптә фронт өчен җылы киемнәр җыю игълан ителде. Әнидән яшереп мин үземнең кышкы бүрегемне илттем, ә кышны исә әтинең кепкасын киеп үткәрдем.

Мин токарь булып эшләгән механика цехында миңа өч метр фланель алу өчен талон бирделәр. Базарда мин ул талонны иске бүреккә алыштырдым.

Цехта эшләгәндә кыенлыклар күп булды. Эшчеләр ике смена эшләделәр. Фронтка снарядлар кирәк иде. Цех начальнигы Сурен Абросимович Назарян тәүлек әйләнәсендә эшләде. Ике ай буена ул цехтан чыкмыйча эшләде, шунда кунды. Цехта снарядларның беренче партиясе чыга башлагач кына Сурен Абросимовичның йөрәге түзмәде, ул өстәл артында утырган килеш үлде.

Сугыш ахырында мин комсомол ротасы белән фронтка килдем. Сугышларның берсендә сержант мине үз янына чакырып алды. Ул авыр яраланган иде. «Минем винтовкамны ал, ул төз ата һәм башыңа бүрекне ки. Себер укучылары җибәргәннәр»,— диде.


Мин бүрекне кулга алдым һәм аның эчендә әнием кулы белән чигелгән исем-фамилиямне укыдым.

— Үзегезнең бүрекне шулай таныдыгызмы?— дип кыенсынып кына сорады Федя Теплов.

— Таныдым.

Художник ИЛЬДАР АХМАДЕЕВ (Рәссам ИЛДАР ӘХМӘДИЕВ)





— Булмас,— дип партада кыбырсынды Семен Кузьмин.

— Сеня, дәрестән соң минем белән өйгә кайтырсың, мин сиңа аны күрсәтермен. Армиядән кайтканнан бирле бүрекне саклыйм. Сугыш истәлеге.

Балалар минем өйгә килделәр. Мин шкафтан консерв банкасыннан ясалган йолдыз кадалган бүрекне алып күрсәттем.

Сеня бүрекне мәктәп каршында әле яңа гына оешкан музейга бүләк итүемне сорады. Ул әле дә анда, сугыш даны экспонатлары белән бергә саклана.

Урысчадан ***ЛИЛИЯ СӘХАПОВА*** *тәрҗемәсе.*







Аркадий Мельников

ШАПКА

До конца урока осталось несколько минут, но ребята наперебой просят рассказать что-нибудь не по программе, а из своей жизни. Много я им говорил о войне, когда еще совсем молодым солдатом воевал на фронте, но жажда узнавать новое постоянно живет в человеке, а в детях особенно.

— Ладно, ребята, уговорили.— И вспомнил я историю с шапкой...

Однажды рано утром открыл я окно: в прохладном утреннем воздухе пахло арбузом, днепровские волны тревожно бились о берег.

Но вдруг над крышей дома я увидел самолеты с фашисткими крестами. Полетели бомбы. Значит, война. Я записался в ополчение. Мы несли караульную службу: ловили диверсантов-парашютистов. Форма у них была наша, новая-новая, скрипели сапоги и ремни на гимнастерках. Через два месяца получили приказ: погрузить в эшелон ценное оборудование военного завода и наладить выпуск снарядов в далеком сибирском тылу. Я взял с собой учебники, а из теплых вещей пальто и шапку. Наш эшелон был последним. Только мы проехали мост через Днепр, раздалось несколько взрывов и мост рухнул в воду. Фашистские стервятники, разбомбившие мост, преследовали нас до Ростова. Они хотели уничтожить наш эшелон, бомбы рвались в разных местах, но попасть в эшелон им не удалось.

В школе лютой зимой сорок первого года был объявлен сбор теплых вещей для фронта. Тайком от матери я отнес свою зимнюю шапку и зимовал в отцовской кепке.

В механическом цехе, куда я поступил работать токарем, мне выдали талон на получение трех метров фланели. На базаре я обменял этот талон на старую шапку.

Трудностей в цеху было много. Рабочие работали по две смены. Фронту нужны были снаряды. Начальник цеха Сурен Абросимович Назарян работал круглые сутки. Два месяца он не выходил из цеха, там же и спал. Но как только цех выпустил первую партию снарядов, не выдержало сердце Сурена Абросимовича, и прямо за столом он умер.

И вот уже в конце войны с комсомольской ротой я приехал на фронт. В одном из боев сержант подозвал меня к себе. Он был тяжело ранен.

— Вот возьми мою винтовку, очень метко стреляет... и шапку. Прислали сибирские школьники...

Взял я в руки шапку и увидел на подкладке вышитые мамой слова: мое имя и моя фамилия.


— Так-таки и шапку свою узнали?— робея спросил Федя Теплов.

— Узнал.

— Не может быть,— подпрыгнул на парте Семен Кузьмин.

— Сеня, пойдешь после уроков ко мне домой, я тебе ее покажу. Вернулся из армии, а шапку





берегу. Фронтовая память.

Пришли ко мне домой ребята. Достал я из шкафа зимнюю шапку со звездочкой из консервной банки.

Сеня попросил меня подарить ее в недавно организованный при школе музей. Она и сейчас там хранится рядом с экспонатами боевой славы.

Художник ИЛЬДАР АХМАДЕЕВ (Рәссам ИЛДАР ӘХМӘДИЕВ)
Художник ЮРИЙ ДЕНИСОВ (Рәссам ЮРИЙ ДЕНИСОВ)




БАЛАЛАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ
ҮСЕМЛЕКЛӘР НИЧЕК ТУКЛАНАЛАР?
CO_2
ПОТАШ
ЖЕЛЕЗО
СЕРА
МАГНИЙ
АЗОТ
МИКСЕР
H_2O
CO_2
ВОДА
H_2O



Художник ЗАГИР ХАКИМОВ
(Рәссам ЗАҺИР ХӘКИМОВ)

ИЗУЧАЕМ ЯЗЫКИ
ТЕЛЛӘРНЕ ӨЙРӘНӘБЕЗ

ЮНЫЕ ДРУЗЬЯ!

УРОК 6 ДӘРЕС

«ИЗУЧАЕМ ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК»

ШЕСТОЙ УРОК

1. Сорауларга җавап бирегез: (Отвечайте на вопросы)

КЕМНЕҢ?


Бу — *кемнең* китабы?



Бу — *Әнәснең* китабы.

НӘРСӘНЕҢ?

Бу — *нәрсәнең* алмасы?



Бу — *алмагачның* алмасы.



Бу — *кемнең* күлмәге?

Бу — *Мөнирәнең* күлмәге.

Бу — *нәрсәнең* бите?


Бу — *китапның* бите.



КЕМГӘ?

Вәкил алманы *кемгә* бирә?

Вәкил алманы *Ләйләгә* бирә.



НӘРСӘГӘ?



Галим *нәрсәгә* яза?

Галим *дәфтәргә* яза.

КАЯ?

Фәрит һәм Миләүшә *кая* баралар?



Фәрит һәм Миләүшә *мәктәпкә* баралар.

СҮЗЛЕК

кемнең — кого
нөрсөнең — чего
кемгө — кому
нөрсөгө — чему
кая — куда
мәктәпкә — в школу
алма — яблоко
күлмөк — платье
китапның бите — страница книги
бирә — дает
яза — пишет
баралар — идут

2. Укып чыгыгыз, урыс теленә тәрҗемә итегез:
(Прочитайте и переведите на русский язык).

курчак — кукла
бар — есть, имеется
агач — дерево
агачлар — деревья
яфрак — лист

Зөһрәнең курчагы бар.
Салихның пәкесе яңа.
Агачның яфрагы яшел.
Балалар урманга киттеләр.
Камил Зәйнәпкә чәчәкләр бирә.

чәчәкләр — цветы
балалар — дети
урман — лес
киттеләр — ушли
яшел — зеленый

3. Татар телендә тартым белән төрләнеш. (Категория принадлежности.)

	БЕРЛЕК (единственное число)	**КҮПЛЕК** (множественное число)
БЕРЕНЧЕ ЗАТ (первое лицо)	*ат-ым (моя лошадь)* *алма-м (мое яблоко)*	*ат-ыбыз (наша лошадь)* *алма-быз (наше яблоко)*
ИКЕНЧЕ ЗАТ (второе лицо)	*ат-ың (твоя лошадь)* *алма-ң (твое яблоко)*	*ат-ыгыз (ваша лошадь)* *алма-гыз (ваше яблоко)*
ӨЧЕНЧЕ ЗАТ (третье лицо)	*ат-ы (его, ее лошадь)* *алма-сы (его, ее яблоко)*	*(аларның) ат-ы (их лошадь)* *(аларның) алма-сы (их яблоко)*

Төрләндерегез (просклоняйте):

	БЕРЛЕК	**КҮПЛЕК**
I ЗАТ	*гөл — ем (мой цветок)* *бүлмә-м (моя комната)*	*гөл — ебез (наш цветок)* *бүлмә-без (наша комната)*
II ЗАТ	*гөл... (...)* *бүлмә... (...)*	*гөл... (...)* *бүлмә... (...)*
III ЗАТ	*гөл... (...)* *бүлмә... (...)*	*гөл... (...)* *бүлмә... (...)*

4. Укыгыз, җөмләләрне татарча әйтегез:

Я читаю и пишу.
Мы изучаем татарский язык.
Дети учатся в школе.


5. Мәкальләрне укыгыз һәм ятлагыз:

Ананың балага биргән иң зур бүләге — тел.
Иң татлы тел — туган тел, анам сөйләп торган тел.
Җайлы сүз җан эретә.

Урок ведет доктор
филологических наук,
профессор КГУ ***ВАХИТ ХАКОВ.***



ЕЛ



Муса Җәлил

КАТЫЙЛЬГА

МИН ТЕЗ ЧҮКМӘМ, КАТЫЙЛЬ, СИНЕҢ АЛДА,
КӨЛ ИТСӘҢ ДӘ, ТОТКЫН ИТСӘҢ ДӘ.
КИРӘК ИКӘН, ҮЛӘМ АЯГҮРӘ,
БАЛТА БЕЛӘН БАШЫМ КИССӘҢ ДӘ.


МЕҢЕН ТҮГЕЛ, БАРЫ ЙӨЗЕН ГЕНӘ
ЮК ИТӘЛДЕМ СИНЕҢ СЫҢАРНЫҢ.
ҺӘМ ХАЛКЫМНАН, КАЙТКАЧ, ШУНЫҢ ӨЧЕН
МИН ТЕЗЛӘНЕП ГАФУ СОРАРМЫН.

1943, ноябрь.

Художник ЗАГИР ХАКИМОВ (Рәссам ЗАҺИР Хәкимов)

Муса Джалиль


ПАЛАЧУ




НЕ ПРЕКЛОНЮ КОЛЕН, ПАЛАЧ, ПЕРЕД ТОБОЮ,
ХОТЯ Я УЗНИК ТВОЙ, Я РАБ В ТЮРЬМЕ ТВОЕЙ.
ПРИДЕТ МОЙ ЧАС — УМРУ. НО ЗНАЙ; УМРУ Я СТОЯ,
ХОТЯ ТЫ ГОЛОВУ ОТРУБИШЬ МНЕ, ЗЛОДЕЙ.

УВЫ, НЕ ТЫСЯЧУ, А ТОЛЬКО СТО В СРАЖЕНЬЕ
Я УНИЧТОЖИТЬ СМОГ ПОДОБНЫХ ПАЛАЧЕЙ,
ЗА ЭТО, ВОЗВРАТЯСЬ, Я ПОПРОШУ ПРОЩЕНЬЯ,
КОЛЕНА ПРЕКЛОНИВ, У РОДИНЫ МОЕЙ.

1943, ноябрь.





Художник ЗАГИР ХАКИМОВ
(Рәссам ЗАҺИР ХӘКИМОВ)

Куык, салам бөртеге һәм чабата



(Әкият)

Яшәгән ди, булган ди куык, салам бөртеге һәм чабата. Көннәрдән беркөнне алар урманга утынга киткәннәр. Елга буена җиткәч, аргы якка ничек чыгарга белми, аптырап калганнар.

Озак баш ваткач, чабата куыкка:

— Куык, әйдә сиңа утырып йөзеп чыгабыз! — дигән.

— Юк инде, чабата! — дип каршы төшкән аңа куык. — Әнә салам бөртеге елга аша сузылсын, аның буенча без дә чыгарбыз.



Салам бөртеге бер ярдан икенче ярга сузылган. Чабата елганы кичә генә башлаган, салам шундук сынып та төшкән. Чабата чапылдап суга егылган. Ә куык исә зур корсагын тотып хихылдап көлгән дә көлгән һәм кинәт шартлаган.

ФИРДӘВЕС ЗАРИФ
тәрҗемәсе.

Художник СВЕТЛАНА ПРИВИНА
(Рәссам СВЕТЛАНА ПРИВИНА)

Волшебный мир

Пузырь, соломинка и лапоть





(Сказка)

Жили-были пузырь, соломинка и лапоть.

Пошли они в лес дрова рубить. Дошли до реки и не знают, как перейти через реку.

Лапоть говорит пузырю:

— Пузырь, давай на тебе переплывем!

— Нет, лапоть! Пусть лучше соломинка перетянется с берега на берег, мы по ней перейдем.

Соломинка перетянулась с берега на берег. Лапоть пошел по соломинке, она и переломилась. Лапоть упал в воду.

А пузырь хохотал, хохотал, да и лопнул.

Художник АЛЛА АЙСИНА
(Рәссам АЛЛА АЙСИНА)

Тылсымлы дөнья

Волшебный мир



Тычкан баласы һәм Карандаш

(Әкият)

Борын-борын заманда Вованың өстәлендә бер Карандаш яшәде. Вова еш кына төрле рәсемнәр ясый, ә Карандаш исә ул теләгән һәр сурәтне карышусыз кәгазьгә төшерә. Моның өчен Вова үзенең Карандашын бик яратты.

Беркөнне, Вова йоклап ятканда, өстәл өстенә Тычкан баласы менде. Карандашны күргәч, аны эләктерде дә үзенең өненә сөйрәп алып кереп китте.

— Зинһар, мине җибәр инде! — дип ялынды Карандаш.— Нигә кирәк инде мин сиңа? Мин — агач, мине ашарга ярамый...

— Мин сине кимерәм! — диде Тычкан баласы.— Минем тешләрем кычыта һәм мин гел нәрсәдер кимереп торырга тиеш. Менә шулай! — Һәм Тычкан баласы, авырттырып, Карандашны тешләп тә алды.

— Ай,— дип кычкырды Карандаш.— Алайса соңгы тапкыр берәр нәрсә ясарга рөхсәт ит инде, аннан соң теләсә нишләрсең?..

— Әйдә шулай булсын,— дип килеште Тычкан баласы.— Яса! Ләкин аннан соң мин барыбер сине кимереп бетерәм.

Карандаш авыр сулады да бер түгәрәк ясап куйды.

— Бу сырмы? — дип сорады Тычкан баласы.

— Бәлки сырдыр,— диде Карандаш һәм тагын өч нәни түгәрәк сызып куйды.

— Әлбәттә, сыр, ә бу түгәрәкләр андагы тишекләр,— дип фараз кылды Тычкан баласы.

— Бәлки, тишекләрдер дә,— дип килеште аның белән Карандаш һәм тагын бер зур түгәрәк ясап куйды.

— Бу алма! — дип кычкырды Тычкан баласы.

— Бәлки алмадыр да,— диде Карандаш һәм тагын берничә озын түгәрәк ясап куйды.

— Мин беләм, бу тәмле казылык,— дип кычкырды Тычкан баласы, селәгәйләрен агызып.— Әйдә, тизрәк бетер инде, югыйсә минем тешләрем бик яман кычыта башлады...

— Бераз гына көт инде,— диде Карандаш һәм рәсем ясавын дәвам итте. Аңа карап торган Тычкан баласы куркуыннан кинәт кычкырып җибәрде: — Бу бит... мәчегә охшаган. Бүтән ясама!

Ә Карандаш исә ул арада зур мыекларны ясарга да өлгерде...

— Бу чын мәче ич! — дип чыелдады коты алынган Тычкан баласы.— Коткарыгыз! — һәм ул чинап өненә кереп качты.

*Урысчадан **ЛИЛИЯ СӘХАПОВА** тәрҗемәсе.*

МЫШОНОК И КАРАНДАШ

(Сказка)

Жил-был на столе у Вовы Карандаш.

Вова часто рисовал всякие картинки, и Карандаш послушно рисовал все, что хотел Вова. За это Вова очень любил свой Карандаш.

Однажды, когда Вова спал, на стол забрался Мышонок. Увидел Карандаш, схватил и потащил к себе в норку.

— Отпусти меня, пожалуйста! — взмолился Карандаш.— Ну зачем я тебе нужен? Я деревянный и меня нельзя есть.

— Я тебя буду грызть! — сказал Мышонок.— У меня чешутся зубы, и я все время должен что-нибудь грызть. Вот так! — И Мышонок больно укусил Карандаш.

— Ой! — сказал Карандаш.— Тогда дай в последний раз что-нибудь нарисовать, а потом делай что хочешь.

— Так и быть,— согласился Мышонок,— рисуй! Но потом я тебя все равно изгрызу на мелкие кусочки.

Вздохнул тяжело Карандаш и нарисовал кружок.

— Это сыр? — спросил Мышонок.

— Может быть, и сыр,— сказал Карандаш и нариовал еще три маленьких кружочка.

— Ну конечно, сыр, а это дырочки в нем,— догадался Мышонок.

— Может быть, и дырочки,- согласился Карандаш и нарисовал еще один большой кружок.

— Это яблоко! — закричал Мышонок.

— Может быть, и яблоко,— сказал Карандаш и нарисовал несколько вот таких длинных кружочков.


— Я знаю, это сардельки! — закричал, облизываясь, Мышонок.— Ну, кончай скорее, у меня ужасно чешутся зубы.

— Подожди минуточку,— сказал Карандаш, и, когда он начал рисовать вот эти уголочки, Мышонок закричал: — Это похоже на ко... Не рисуй больше!

А Карандаш уже нарисовал большие усы...

— Да это настоящая кошка! — пискнул испуганный Мышонок.— Спасите! — И бросился к себе в норку.

С той поры Мышонок оттуда носу не показывал.



Художник АЛЕКСАНДР АЛЕШИН
(Рәссам АЛЕКСАНДР АЛЕШИН)

Мирас
Наследие

Габдулла Тукай

Шүрәле

(Шигъри әкият)

II

Җәй көнен яздым бераз; язмыйм әле кыш, көзләрен,
Алсу йөзле, кара кашлы, кара күзле кызларын.
Бу авылның мин җыен, мәйдан, сабаны туйларын
Язмыйм куркып, еракларга китәр дип уйларым...
Тукта, мин юлдин адашканмын икән бит, күр әле;
Әллә ник истән дә чыккан, сүз башым бит: «Шүрәле».
Аз гына сабыр ит әле, и кариэм! — хәзер язам;
Уйласам аулымны, гакълымнан да мин хәзер язам.

(Дәвамы бар)

Шурале

(Поэтическая сказка)

II

Описал стихами лето: осень, зиму — не хочу,
О красавицах румяных, чернобровых промолчу,
Сабантуй и гулянья я описывать боюсь,
Как начну, с пути рассказа непременно я собьюсь!
Стой-ка, все же ненароком потерял я нить, гляди:
Заголовок где-то сзади, суть рассказа — впереди.
Потерпи еще немного, о читатель! Расскажу,
Вспомнив милую деревню, тотчас как с ума схожу!

(Продолжение следует)

Художник ЗУФАР ХАКИМОВ
(Рәссам ЗӨФӘР ХӘКИМОВ)

Головоломки Баштаткычлар

Кадерле сабыйлар! Бу рәсемне төсле буяулар белән буягыз!
Дорогие дети! Раскрасьте этот рисунок цветными красками!

БИЗӘГЕЧ

РАСКРАСКА



ДОРОГИЕ ДЕДУШКИ И БАБУШКИ!

С 1 июля 1994 года начал выходить детский иллюстрированный, литературно-художественный журнал «Сабыйга» («Ребенку») на татарском и русском языках. Детский журнал включен в Каталог газет и журналов Республики Татарстан и Каталог ЦПА «Роспечать» Российской Федерации на 2-ое полугодие 1995 года. Индекс—73954. Подписка на журнал производится без каких-либо ограничений во всех отделениях связи Республики Татарстан, Российской Федерации и в государствах СНГ. Спешите осчастливить ваших внуков!

Редакция детского журнала «Сабыйга».

Головоломки Баштаткычлар



ТАСФИР
«ТАСФИР» — НАДЕЖНЫЙ ДРУГ!
«ТАСФИР» сегодня — это около миллиарда рублей страховых премий в год, сотни миллионов рублей запасных и резервных фондов, 50 видов страховых услуг для предприятий, банков, граждан, 3,8 млн. договоров страхования с гражданами республики.
Наша фирма проводит добровольное страхование гражданской ответственности для владельцев транспортных средств. Этим видом страхования могут воспользоваться все транспортные организации, предприятия и физические лица республики.
«ТАСФИР» предлагает широкий набор договоров коллективного страхования в пользу своих сотрудников. Это договора страхования жизни на различные сроки на случай травматизма, установления инвалидности, потери рабочего места (на случай безработицы), возвратное и комплексное страхование с начислением бонуса (процента) и целый ряд других страховых услуг.
«ТАСФИР» всегда готов помочь Вам! Наш адрес: Татарская республиканская страховая фирма «ТАСФИР», 420503, г. Казань, ул. Куйбышева, дом 13. Телефоны: Приемная — 32-11-65, Страхование имущества граждан — 32-69-44, Личное страхование — 32-26-14, Страхование имущества госпредприятий и кредитов — 32-63-67.

Индекс 73954



Цена договорная